# *8 сыйныф*
# *Хәл фигыль.*

**Тәрҗемә итегез:**

1. Укып бел, белеп укы, укый белә, укый-укый әйтә;
2. Эшләп карыйбыз, карап эшлибез, эшли-эшли арып беттек;
3. Санап алыгыз, алып санагыз, саный-саный буталды;

# Хәл фигыльнең
# 3 төре

## *Хәл фигыль +гач/гәч, +кач/кәч*

Аша+гач = ашагач

Кайт+кач = кайткач

Фигыль = хәл фигыль

## Действие основного глагола совершается всегда по завершении действия деепричастия.

**Например:**

***Әти эштән <u>кайткач</u>, без кичке аш <u>ашарга утырдык.</u>***

***Кайткач–Хәл фигыль***(деепричастие)

***Ашарга утырдык – Төп фигыль***

(основной глагол)

# 1нче күнегү.

**Үрнәк: Уйла – уйла<u>гач</u>**

- Яшә-
- Котла-
- Чап-
- Сөйләш-
- Тырыш-
- Су сип-
- Җыештыр-

Хәл фигыльләрне кулланып ике җөмлә төзегез.

# 2нче күнегү.

## Хәл фигыльләрне табыгыз.Тәрҗемә итегез.

1. Урманга баргач, мин кошлар җырын тыңларга яратам.
2. Ветераннар залга җыелгач, концертны башлап җибәрделәр.
3. Имтиханнар башлангач, ул урамда күп йөрми, телевизор да карамый башлады.
4. Дәресләрне әзерләп бетергәч, әнидән урамга чыгарга рөхсәт сорадым.

**<u>Знче күнегү.</u>**

**Җәяләрне ачып, хәл фигыльләр ясап, җөмләләрне күчереп языгыз.Тәрҗемә итегез.**

- Җиләккә (бар), бик көчле яңгыр ява башлады.
- Абыем, әниебезнең туган көненә кайта (алма), телефоннан шалтыратып котлады.
- Ул үзе миннән ярдәм (сорама), мин дә ярдәм итмәдем.

# Өй эше.

***Допишите предложения. Выделите деепричастие и основной глагол.***

*Татар телен яхшы өйрәнгәч, ..........*

*Яңа дуслар белән танышкач, ...........*

*Тәрәзә төбендәге гөлләргә су сипкәч,.....*

# Хәл фигыльнең 4 төре

# Хәл фигыль.
# -ганчы/гәнче, -канчы/кәнче

Деепричастие на ганчы/гәнче,канчы/кәнче по отношению к действию основного глагола выражает:

1. Предел действий: **син килгәнче** (до того, как ты пришел);
2. Степень завершенности действия: **арганчы эшләдем** (работал пока не устал);
3. сравнения: **монда утырганчы** (чем здесь сидеть);

Этот вид деепричастия как бы устанавливает границу для совершения основного действия или необходимое условие, без которого основное действие не может совершаться. **Например:**
**Мин кайтканчы көтеп тор.** (Подожди пока я не вернусь.)
**Укымыйча утырганчы, дәресләрне әзерләргә кирәк.** (Чем просто так сидеть, надо сделать уроки.)

# 1нче күнегү.

**Үрнәк: Бар – барганчы**

Чап-

Уз-

Башла-

Ычкындыр-

Өйрәт-

Сындыр-

Шаярт-

Мен-

Сиз

# 2нче күнегү.

Запишите деепричастия в 3 столбика:

1.Предел действия;

2.Степень завершенности действия;

3.Сравнение;

**Тәнәфес беткәнче уйнап ал; ашыгып эшләгәнче; белмичә сөйләгәнче;акчаңны биргәнче сана;арганчы биедем;сорамыйча алганчы;туйганчы еладым;кайтып җиткәнче уйландым;тавышы беткәнче җырлады;**